# Бөек Ватан сугышы елларында
# Кырынды авылы тормышы.

**Авылыбыздан киткән сугышчылар, бөтен халык белән берлектә, дошман явына каршы калкан булып күтәрелә. Алар сынатмыйлар, һәрчак алгы сафларда булырга тырышалар, батырлыклары белән танылалар.**

**Авыр , бик авыр еллар иде...Авылда картлар, хатын-кызлар һәм балалар гына калды. Ирләре, ул лары, туганнары зур батырлыклар күрсәткәндә, тылдагы хатын-кызларыбыз үзләрен аямыйча эшләделәр. Аларның батырлыгы сугыш кырында туган батырлыкка тиң. Тормышны алып барырга кирәк-игенен дә игәргә, балаларны да ач-ялангач итмәскә, сугышка төрле җылы киемнәр дә әзерләп җибәрергә кирәк. "һәр удар эш-фашистларны тизрәк тар-мар итү өчен өстәмә көч ул,"-дип эшләделәр авылларда.**

**Фронтны азык-төлек, кием-салым, корал белән тәэмин итүдә, өлкәннәр белән бергә, укытучылары җитәкчелегендә мәктәп балалары да зур фидакарьлек үрнәкләре күрсәтәләр. Бу урында шул елларда мәктәп директоры булып эшләгән Йосыф ага Мусинның үзе язган автобиографиясендәге юлларны мисал итеп китерергә була . "Ул елларда мәктәптә дә, колхозда да иң авыр еллар иде. Мәктәптә укытучы кадрлар җитми. Ачлык, мохтаҗлык сәбәпле күп укучылар дәрескә йөрми. Мәктәпкә килгәннәре дә дәрес бетүгә кечкенә чаналар тартып утын, салам юнәтү ягын карыйлар. Дәреслек, уку-язу әсбаплары юк. Укучылар дәфтәр урынына иске китапларга язалар. Барлыгы 520 укучы булып, мәктәп өч сменада эшли иде.**

**Ә колхозда? Анда бигрәк тә авыр иде. Техника юк. Бөтен эшне хатын-кыз, карт-коры, балалар кулдан башкара. Атлар ачлыктан йөри алмаслык хәлдә, сыерлар, сарыклар егыла. Әле дә хәтердә. Кырык дүртнең язында колхоз бозаулары ачтан үлә башлагач, укучылар белән өйдән-өйгә йөреп, бәрәңге кабыклары, сөт кебек әйберләр җыйдык. Бозаулар исән калды."**

**Ул чорда районыбыз газеталары мәктәпләр тормышын яктыртуга киң урын биргән. Аларның хәр санында диярлек мәктәпләр тормышы, укытучы хәм укучыларның Бөек Җиңүне якынайтуга керткән өлеше турындагы язмалар урын алган.**

“Кырынды мәктәбе укучысы Шәйхенур Гыйльфанов 1940-41 уку елында 1 классны тәмамлагач та колхозда эшли башлады. Аның әтисе Гыйльфан абзый фронтка киткәч, Шәйхенур колхозда тагын да тырышып эшләде. Нәтиҗәдә 1 декабрьгә кадәр аның 307 хезмәт көне булды.”

Н.Хузин. 1942 ел,8 декабрь.

“Яңалиф” колхозының 1943 елда мул иген уңышы алырга тырышучы 2 һәм 4 бригадалары( бригадирлары Ахметшин һәм Салаев) язгы чәчүгә әзерлек эшенә нык әһәмият бирәләр. Бу бригадалар авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны күптән тулысынча тәмамладылар. Хәзер алар агротехника чаралары планын үтәү өстендә уңышлы эш алып баралар”.

К. Җамалиева. 1943 ел, 11февраль.

“Яңалиф” колхозының ат караучылары Октябрь алды социалистик ярышына кушылып атларны яхшы тәрбияләү турында конкрет йөкләмәләр алганнар иде. 1 бригаданың атлар караучысы иптәш Нәсифуллина үзенә беркетелгән атларны яхшы каравы белән бу ярышта җиңүчеләрдән булып чыкты. Иптәш Нәсифуллина үрнәгендә, 3 бригада ат караучысы икенче урынны яулап алды, 2бригадада да эш канәгатьләнерлек бара.”

Х.Рамазанов. 1942 ел, 26 июнь.

“Кырынды авыл советына караган колхозларның члennары батыр сугышчыларыбызга бүләк итеп 30 пар эчке кием, 15 пар бияләй, күп кенә ит, май хәзерләделәр һәм бүләкләр алу өчен 9000 сум акча җыеп тапшырылды.”

Т.Мөхәммәтҗанов. 1942 ел, 22 февраль.

«Буденный исемендәге колхозда соңгы көннәрдә утау эшләре яхшырды. Бу уңай белән үткәрелгән 2 көнлек өмәдә колхозчылар гаять зур активлык белән катнаштылар. Алар эшкә иртән 5 сәгатьтә китеп, кич 9 сәгатьтә генә кайттылар. Ике көн эчендә227 гектар иген чүп үләннәреннән арындырылды һәм беренче кат утау тәмамланды. Тырышып эшләгәннәргә ни дисең!?”

Ф.Абитов, 1943 ел, 8 июнь.

Сугыш еллары еракта калды. Ләкин кешеләр йөрәгендә сугыш калдырган яра-җәрәхәтләр һаман да сыкрый әле. Йөрәк яраларыннан һаман да кан саркып тора. Сөекле улларын, яраткан ирләрен югалткан аналарның, хатыннарның кайгы-хәсрәте мәңге онытыласы, алар йөрәгендә сугыш калдырган яра мәңге төзәләсе түгел.

**Сугыш афәтен башыннан кичергән кешеләр кабат сугыш булуын беркайчан да теләмәсләр.Шунлыктан илебез халыклары һәрчак сугышка каршы.**

**Җиңү көнен билгеләп үткәндә без һәлак булганнарның якты истәлеге алдында: безгә тынычлык кадерле, безгә һәр кеше кадерле дибез. Халыклар дуслыгын, милләтара татулыкны ныгыту безнең изге бурычыбыз булды һәм шулай булып кала да. Кешелек дөньясы тарих сабакларын онытырга тиеш түгел. Без халкыбызның менә шул батырлык һәм фидакарьлекләрен, зур югалту һәм корбаннарын киләчәк буыннарга да сөйләп калдырырга бурычлы.**

## Сугыш елларында колхозда җитәкчеләр еш алышынып торган, шулай да халыкны олы эшкә өндәп торучылар:

**Галиәскар Садыйков**
**Афанасий Сериков**
**Мария Королева**
**Иван Костенков**
**Иван Кросноперов**
**Иван Батокин**
**Петр Гребенщиков**
**Галиулла Сәлимуллин**
**Вәли Әхмәдиев**
**Нигъматулла Сөләйманов**
**Шәех Әхмәтов**
**Хаҗи Вәлиев**
**Павел Дресвянников**

**Бригадирлар, ферма мөдирләре:**

**Разия Шабаева**
**Газизә Закирова**
**Галимә Нигъматуллина**
**Анна Дресвянникова**
**Гөлбәһәр Булатова**